РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29 гыйнвар 2021 ел №5

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73-нче номерлы карары, «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 3 номерлы карарын 2021 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, махсус мәгълүмат стендларында, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче Р.Ф.Нотфуллин

Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районы Кукмара шәһәре
Башкарма комитетының 2021 елның 29
гыйнварындагы 5-нче номерлы
карарына 1 нче кушымта

**2021 елның 01 февраленнән**
**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең**
**бәясе**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2743,72 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетне) зиратка илтү | 882,97 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2798,29 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районы Кукмара шәһәре
Башкарма комитетының 2021 елның 29
гыйнварындагы 5-нче номерлы
карарына 2нче кушымта

**2021 елның 01 февраленнән**
**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең**
**бәясе**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү (киендерү) | 115,52 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2628,21 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 882,96 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2798,29 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |